*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (59) Февраль, 2024 нче ел

Бу санда

*Фән олимпиадалары көндәлеге* 2

*Гаилә-бала-гимназия арасындагы дуслык күпере* 2

*Гаилә – көндәлек проза ул* 3

*Кош канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле* 4

*Гимназиядә хәрби-патриотик айлык* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



***Хөрмәтле гимназия ир-егетләре, укучы егетләр!***

*Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан ир-егетләребезне котлыйбыз. Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана. Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез.*

***"Тылсым+" газетасы редколлегиясе***

## «Ел укытучысы – 2024» конкурсының зона этабы







Түбән Кама муниципаль районының "Адымнар - Түбән Кама күптелле гимназиясе"ндә Бөтенрәсәй "Ел укытучысы" конкурсы регион этабының зона туры үтте. Гимназиябезнең ике мөгаллиме - Фәхертдинова Л.Ә., башлангыч сыйныфлар укытучысы, Әгъләмов Р.Б., физика укытучысы һөнәри осталыкта көч сынашты. Алар дәрес, осталык классы күрсәттеләр. Җиңүчеләр конкурсның регион этабында чыгыш катнашачак. Бәйгедә катнашучыларга уңышлар телибез!

## «Ел укучысы - 2024»



Башлангыч сыйныф укучылары арасында сәләтле балаларны ачыклау, һәрьяклап үсеш алган шәхес тәрбияләүдә нәтиҗәлелеккә ирешкән мөгаллимнәрне барлау максатында "Ел укучысы" бәйгесенең финал этабы үтте.

Гимназия укучылары: Фазлиева София (4 нче а сыйныф укучысы) җиңүче, Гәрәев Әмин (4 нче в сыйныфы укучысы) 1 нче урынга лаек булдылар. Укытучылары Алсу Рауиловнаны, Зөлфия Дөлфәтовнаны, җиңү яулаган укучыларны зур уңышларга ирешүләре белән котлыйбыз!

## English Fest




Гимназия базасында инглиз телендә "English Fest" фестивале үтте. Финалга үткән мәктәпләр инглиз телендә, инглиз язучыларының әсәрләреннән театр күрсәттеләр. Гимназиялеләр абсолют җиңү яуладылар. Укучылар сәхнәдә инглиз телендә иркен сөйләшүләре, матур костюмнары белән тамашачыны таң калдырдылар.

Җитәкчеләре: Миннегалиева Л.Н., Мөхәммәтҗанова Г.И.

# ФӘН ОЛИМПИАДАЛАРЫ КӨНДӘЛЕГЕ









***Фән олимпиадалары җиңүчеләрен котлыйбыз!***

**Россиякүләм һәм Республикакүләм фән олимпиадалары февраль аенда да дәвам итте. Соңгы нәтиҗәләр буенча, барлыгы 27 укучы призлы урыннар яулаган.**

Биология фәне буенча үткән олимпиада да 8 нче а сыйныфыннан **Латипова Алинә**, 9 нчы в сыйныфы укучылары **Газетдинова Азалия**, **Газетдинова Адилә** Россиякүләм олимпиаданың регион этабы призёрлары (укытучылары – Бариева Л.Ф.), рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендә укучылар өчен үткәрелгән татар теле буенча республика олимпиадасының йомгаклау этабында 5 нче а сыйныфы укучысы **Мәрданова Мәрьям**, 7 нче б сыйныфы укучысы **Галимова Айназ**, 10 нчы сыйныф укучылары **Галиева Сөмбел**, **Мирсалихова Зәринә**; шул ук олимпиаданың татар әдәбияты фәненнән 10 нчы сыйныф укучылары **Нәргизә Авзалова, Зәринә Мирсалихова** призлы урыннар яуладылар (укытучылары – Авзалова З.З., Ямалова Г.Ф.). 7 нче в сыйныфы укучысы **Айгильдина Зарина**, 8 нче б сыйныфы укучысы **Садриева Рузилә** республика олимпиадасының рус теле буенча йомгаклау этабының призерлары (укытучылары – Хәйруллина Ч.А., Фазлыева А.В.), экология фәне призерлары: 10 нчы сыйныфтан **Галиева Сөмбел**, 11 нче сыйныфтан **Бариева Илина** (укытучылары – Бариева Л.Ф.). Рус мәктәпләренең рус төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен үткәрелгән татар теле буенча республика олимпиадасының йомгаклау этабында 11 нче сыйныф укучысы **Асылгараева Анжела**, 6 нчы а сыйныфы укучысы **Асманова Ирина** призер (укытучылары Мирзамуратова Г.М., Ямалова Г.Ф.), 10 нчы а сыйныфы укучылары **Сәйфуллин Рушан** физик тәрбия (укытучысы – Булатов Д.Д.), **Шәрипов Булат** хокук фәненнән (укытучысы - Мирзаянов А.Ф.), **Сөләйманова Диана** инглиз теленнән (укытучысы – Мөхәммәтҗанова Г.И.), **Садриев Илназ** ОБЖ фәненнән (укытучысы - Галиев З.З.) Россиякүләм олимпиаданың регион этабы призерлары.

***Призерларны һәм аларга белем бирүче мөгаллимнәребезне чын күңелдән тәбрик итәбез. Олимпиадаларда җиңүчеләргә киләчәктә уңышлар һәм сәламәтлек телибез!***













## ГАИЛӘ-БАЛА-ГИМНАЗИЯ АРАСЫНДАГЫ ДУСЛЫК КҮПЕРЕ




***Гаилә. Нинди күркәм, күңелгә йомшак сүз бу! Нәрсә соң ул гаилә? Гаилә - Гадел, Акыллы, Ихтирамга Лаек Әти-әни дигән сүзләр җыелмасы.***

Әйе, баланың ничек тәрбияләнүе, кайсы сыйфатларының ачылуы гаилә тәрбиясеннән тора. Ләкин гаилә ул ниндидер үз эченә генә бикләнгән урын түгел. Гаилә җәмгыять белән турыдан-туры бәйләнештә.

Төрле гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны җыя торган кечкенә “дәүләт” ул - уку йорты. Әти-әниләр балалары белем алучы уку йортлары белән тыгыз элемтәдә торырга тиешләр.

13 нче февраль көнне гимназиядә Гаилә елы һәм "Гаилә һәм мәктәп-ышаныч җепләре" муниципаль проекты кысаларында 7 нче в сыйныфы укучылары, аларның әти-әниләре белән берлектә "Директор белән иртәнге аш" исеме астында, гимназия директоры Мирзаянов Азат Фәрит улы катнашында эшлекле очрашу үтте.

Очрашуны сыйныф җитәкчесе гаилә турында гыйбрәтле кыйсса сөйләве белән башлап җибәрде.

"Без мәктәп һәм ата-аналар арасындагы мөнәсәбәтләрне формаль түгел, ә эчкерсез һәм җылы итәргә, бу мөнәсәбәтләрдә психологик уңайлылык тудырырга омтылабыз", - диде әңгәмә вакытында Азат Фәритович.



Шәхес тәрбияләүдә гаилә һәм мәктәп бердәмлеге, шулай ук балаларның характеры, белеме, әхлак дәрәҗәсе хакында җентекләп сөйләшү дә җылы атмосфера астында үтте. Әниләр, укучылар үзләренең сорауларына тиешле җаваплар кабул иттеләр. Очрашу ахырында, гаиләләр баласы белем ала торган уку йорты белән тыгыз элемтәдә торырга тиеш дигән нәтиҗә ясалды.

Шундый ук очрашу 11 нче сыйныф укучылары, аларның әти-әниләре белән дә үтте. Очрашу вакытында гаилә кыйммәтләре, традицияләре турында әңгәмә корылды. Азат Фаритович әти-әниләрнең сорауларына җавап бирде. Балалар Гаилә елы символын әти-әниләренә бүләк иттеләр.



## ГАИЛӘ – КӨНДӘЛЕК ПРОЗА УЛ

***Гаилә – рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне саклаучы, ата-бабалар тәҗрибәсен, тәрбиясен олы хәзинә итеп кадерләп торучы, буыннарны өзелмәс чылбыр белән бәйләүче.***

**Гөлназ Мирзасалихова, башлангыч сыйныфлар укытучысы:** “Гаилә ул кешенең матди да, рухи да таянычы. Гаилә бәхете ул - бәрәкәтле тормышның асылы. Ә балалар үстергәндә, ни дисәк тә, төп авырлык - тәрбия һәм өй эшләре хатын-кыз җилкәсенә төшә инде”.

**Миләүшә Әмирова, социаль-педагог:** “Гаиләм (ирем, балаларым) минем өчен һәрвакыт беренче урында тора. Безнең гаиләдә үзара аңлашу – ул бер-береңә ышаныч. Әгәр өйдә аңлашылмаучанлык барлыкка килсә, утырып фикер алышабыз.”

**Диләрә Минһаҗева, 11 нче сыйныф укучысы:** “Гаилә - минем өчен бу дөньяның иң гүзәл, иң рәхәт, иң матур җире. Минем терәгем. Ышанычым. Өметем. Мине җылытып торучы әти-әнием”.

**Гөлнара Идиятуллина, башка милләт балаларына татар теле укытучысы:**

“Гаилә ул:

- Әни, абыем мине уйнатмый...
- Әти, курчак, яңа күлмәк, туңдырма алып кайт!
- Улым, уенчыкларыңны җый...
- Кызым, аша инде, тагын бер генә кашык...
- Җаным, эштән кайтышлый ипи, сөт һәм пластырь алып кайт әле, кечкенәсенең бармагына шырпы кадалган, пластырь ябыштырсак кына, еламыйм, ди.
- Нигә телефоныңны алмыйсың? Йөз тапкыр шалтыраттым бит инде!
- Иртәгә башка эшләр планлаштырма, балалар белән калып торасың була, тырнак ясатырга язылдым...
- Әни, кояш нигә түгәрәк? Ә алма? Алайса, груша нигә түп-түгәрәк түгел?
- Бүген нинди тәмле әйбер пешерәсең?
- Кер юылган анда, кайсыбыз элә?
- Синең чират...

Гаилә – менә шундый көндәлек проза ул чынында. Ә шигърияте - менә шушы олы хезмәтне ярату аша кабул итүдә”.

# КОШ КАНАТЫ БЕЛӘН, ГАИЛӘ ТАТУЛЫГЫ БЕЛӘН КӨЧЛЕ

## Минем әтием



Минем әтиемнең исеме Румил. Ул җәйгә утәтү инспекциясендә психолог булып эшли. Үз эшенә җаваплы карый, яратып башкара.

Әтиемнең куллары алтын: агачтан матур кәрҗиннәр, сувенирлар ясый. Аларга күңел җылысы бирә.

Әтием безнең каникулларыбыз, ял вакытларыбыз кызыклы, мавыктыргыч булуы өчен дә тырыша. Табигать кочагында бергәләп ял итү бик тә рәхәт. Гаиләбез белән өмәләр оештырып эшләве үзе бер ял!

Минем әтием бик тырыш, көчле, намуслы кеше. Мин аны бик яратам, аның белән горурланам.

***Солтанова Сылу,***
***2 нче б сыйныфы укучысы***

## Минем гаиләм

Гаилә һәркем өчен кадерле. Безнең гаилә зур түгел, бары дүрт кеше – әти-әни, энем белән мин.

Әтием – Рафит, гаилә башлыгы. "Агромастер" компаниясендә слесарь булып эшли. Эштән арып кайтса да, һәрвакыт укуыбыз белән кызыксына. Киңәшләрен бирә.

Әнием – Фирүзә. Ул хуҗабикә, тәмле ризыклар пешереп, укудан кайтуыбызны көтеп тора. Мин әнием әй эшләрен башкарырга булышам.

Тимур беренче сыйныфта укый. Аның белән бергә уйныйбыз, өй эшләрен эшлибез. Әбиләргә кунакка барырга да җитешәбез.

Мин үземнең гаиләмне яратам. Барыбызга да сәламәтлек телим.

***Бариева Ралинә,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

*****

## Минем гаиләм

Мин, Гамирова Айсылу. Сезгә үземнең матур гаиләм турында язасым килә. Безнең гаиләбез зур һәм тату. Әтием - Наил нефтьче, әнием - Эльмира яшьләр үзәгендә белгеч, абыйларым: Алмаз һәм Нәргиз, гимназиядә белем алалар. Аларның буш вакытлары юк диярлек, укудан соң сәнгать мәктәбенә баян, гитара классына йөриләр. Мин абыйларымны бик яратам. Алар ярдәмчел, тырышлар.

Минем әтием - уңган, көчле, акыллы, эшчән, сабыр кеше. Аның дини белем, вәгазьләр сөйләгәнен дә тыңларга яратам. Әтием үз куллары белән төзегән өебез һәрвакыт балкып тора.



Әнием тәмле ашлар, бәлешләр, тортлар пешерә. Ул өйдә булганда өйнең яме тагын да арта. Әнием гаилә учагын саклаучы, уңган, сөйкемле кеше.

Иртәләрен назлы тавышы белән "Сылуым", "Алтыным" дип назлап уята.

Әти-әниебез безне - өч баласын, җаннарыннан артык күреп яраталар, киләчәккә якты өметләр баглыйлар.

Без өч балалары - аларның киләчәге. Әти-әнине хөрмәт итсәк, аларның сүзләрен тыңласак, киләчәгебез ныклы, көннәребез имин булыр.

***Гамирова Айсылу,***
***1 нче а сыйныфы укучысы***

# ГИМНАЗИЯДӘ ХӘРБИ-ПАТРИОТИК АЙЛЫК



*Квест "Ватан сагында"*



*"Ажаган" хәрби-спорт уены*



*Солдатка хат*





*"Ягез әле, егетләр!"*



*Пневматик коралдан ату ярышы*



*Әфганчылар белән очрашу*


**ТЫЛСЫМ+**

**Февраль, 2024 нче ел**
**№5 (59)**

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям
Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыйпов Илназ
Хәертдинов Ранис

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100